**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **05.12.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Районы Илбәк авыл җирлеге составына керүче Ирекле авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 250 сумга киметеп, 2020 елда үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:
- Ирекле авылында мемориаль такта ясатып урнаштыру;
- торак пункты исеме язылган стела ясатып урнаштыру.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Илбәк авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Әсәдуллина